КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2022 ел, 30 декабрь

г.Казань

№ 1493

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1101 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1101 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 2 июль, 455 нче; 2016 ел, 3 октябрь, 701 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 968 нче; 2017 ел, 13 ноябрь, 866 нчы; 2018 ел, 20 февраль, 102 нче; 2019 ел, 25 февраль, 125 нче; 2019 ел, 5 сентябрь, 775 нче; 2020 ел, 2 апрель, 250 нче, 2020 ел, 6 июль, 555 нче, 2021 ел, 21 апрель, 268 нче, 2021 ел, 6 октябрь, 954 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлеккә түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе милли гвардиясенең хәрби хезмәткәрләре һәм анда хезмәт итүче затлар, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт итүче гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең махсус хәрби операция үткәрү зонасына командировкага җибәрелгән хезмәткәрләре арасыннан махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаилә әгъзалары, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу аркасында һәлак (вафат) булган, югарыда күрсәтелгән категорияләрдәге гражданнар гаилә әгъзалары, инвалид балалар арасыннан (мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен реабилитация үзәкләренә кабул ителгәндә).»;

3.1.1 пунктта таблицага түбәндәге эчтәлекле 7$^1$ пункт өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «7$^1$. | Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе милли гвардиясенең хәрби хезмәткәрләре һәм анда хезмәт итүче затлар, Татарстан Республикасында төзелгән «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт итүче гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең махсус хәрби операция үткәрү зонасына командировкага җибәрелгән хезмәткәрләре арасыннан махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаилә әгъзалары, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу | Татарстан Республикасы хәрби комиссариаты (Татарстан Республикасында хәрби комиссариатлар), Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе яисә башка вәкаләтле орган | законнар нигезендә». |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | аркасында һәлак (вафат) булган, югарыда күрсәтелгән категорияләрдәге гражданнар гаилә әгъзалары, инвалид балалар арасыннан (мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен реабилитация үзәкләренә кабул ителгәндә) социаль хезмәтләр алучының гаилә әгъзасы махсус хәрби операциядә катнашуын раслый торган документ | | |

2. Бу карарның гамәле 2022 елның 20 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин